| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ШУБАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШУБАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«14» ноябрь 2025ел. № 7

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шубан авыл җирлеге Советының 20.12.2010 ел №12 Регламентына өстәмәләр кертү турында**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы белән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шубан авыл җирлеге Уставы нигезендә Балтач муниципаль районының Шубан авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге Советының 20.12.2010 №12 карары белән расланган Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге Советы Регламентына (30.05.2023 №83 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.Регламентның 35 статьясына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктны өстәргә:

«5. Карар кабул иткәндә хәлиткеч тавыш хокукына ия депутатларның "хуплыйм" һәм "каршы" бирелгән тавышлары саны тигез булган очракта, Совет утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.».

2. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны тәэкләндерү, тәзелеш, хокукларны яклау һәм җәмәгать тәртибен саклау буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Глава Шубанского
сельского поселения
Балтасинского муниципального района С.З.Васильева